ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 528-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 528-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2356-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2018, № 54 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяда «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3 статьяда:

а) 3 өлештә «тәртибен» сүзен «тәртипләрен» сүзенә алмаштырырга, «Федераль законның $17^3$ статьясының 1 пунктындагы 2 пунктчасында каралган эшчәнлек төрләренең үзенчәлеген һәм Федераль законның $17^3$ статьясындагы 1 пунктындагы 1 пунктчасына ярашлы рәвештә расланган гомуми таләпләрне исәпкә ала торган» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, шул исәптән аларның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар белән үзара эшләвендә, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмаларына оештыру, мәгълүмати, методик һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, дәүләт һәм муниципаль

учреждениеләргә Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, шулай ук Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актларында каралган формаларда булышлык итү;»;

түбәндәге эчтәлектәге $2^1 – 2^3$ пунктларны өстәргә:

«$2^1$) Федераль законның $17^2$ статьясындагы 2 пункты нигезендә расланган тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге функцияләрен гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешманы билгеләү;

$2^2$) ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәгенә аның тотрыклы эшләвен тәэмин итү максатыннан ярдәм итү, ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм аңа финанс, матди һәм кадрлар белән тәэмин итү, шулай ук Федераль законның $17^4$ статьясында каралган башка формаларда ярдәм итү инфраструктурасын булдыру;

$2^3$) Федераль законның $17^4$ статьясындагы 2 пунктында каралган формаларны исәпкә алып, ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеген билгеләү.»;

в) 5 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге $5^1$ пунктны өстәргә:

«$5^1$) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына кертү өчен мәгълүмат бирү.»;

4) 4 статьяда:

а) 2 пунктта «тәртибен» сүзен «тәртипләрен» сүзенә алмаштырырга, «Федераль законның $17^3$ статьясының 1 пунктындагы 2 пунктчасында каралган эшчәнлек төрләренең үзенчәлеген һәм Федераль законның $17^3$ статьясындагы 1 пунктындагы 1 пунктчасына ярашлы рәвештә расланган гомуми таләпләрне исәпкә ала торган» сүзләрен өстәргә;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, шул исәптән аларның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар белән үзара эшләвендә, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмаларына оештыру, мәгълүмати, методик һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, шулай ук Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актларында каралган формаларда булышлык итү;»;

в) түбәндәге эчтәлектәге 4 – 6 пунктларны өстәргә:

«4) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә координацияләү һәм киңәшмә органнарын формалаштыру;

5) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына кертү өчен мәгълүмат бирү;

6) Федераль законның $17^4$ статьясындагы 2 пунктында каралган формаларны исәпкә алып, ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеген билгеләү.»

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты (алга таба – закон проекты) федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерү максатыннан эшләнде.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 558-ФЗ номерлы Федераль закон) белән «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законга ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде, шул исәптән волонтерлыкка ярдәм итү өлешендә федераль, төбәк, җирле органнарның вәкаләтләре системасы бертөрлелеккә китерелә, дәүләт хакимияте органнары тарафыннан волонтерлык эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чараларының мөмкин булган формалары һәм аларны күрсәтүгә гомуми якын килү юллары билгеләнә.

558-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре исемлеге тулыландырыла, аерым алганда, Россия Федерациясе субъектлары хакимият органнарының ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәкләренә ярдәм күрсәтү, шул исәптән финанс, матди һәм кадрлар белән тәэмин итү буенча һәм башка формаларда ярдәм күрсәтү буенча вәкаләтләре беркетелә.

Закон проекты белән «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына аныклаучы үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

**«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә таләп ителә:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, алар карамагындагы дәүләт учреждениеләренең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярыйлык (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 16 апрелендәге ПУ-223 номерлы Указына үзгәрешләр кертү;

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^2$ статьясындагы 2 пункты нигезендә расланган тәртиптә Россия Федерациясе субъекты территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге функцияләрен гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешманы билгеләү;

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^4$ статьясындагы 2 пунктында каралган формаларны исәпкә алып, ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеген билгеләү.

**«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

Әлеге законны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү» төбәк проектында каралган бюджет ассигнованиеләре хисабына гамәлгә ашырылачак.

Әлеге законны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслау өчен бюджет ассигнованиеләре күләме 17 191,0 мең сум тәшкил итәчәк.